| | |
|---|---|
| СОВЕТ БАГАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАГАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

от 22.09.2020 ел Багай ав. № 2

«Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Багай авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге Башлыгын сайлау турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрьдәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 36 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 24 статьясы, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Багай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 42 статьясы, яшерен тавыш бирү нәтиҗәләре турында хисап комиссиясе утырышының 2 номерлы беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Багай авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТӘ:

1.«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башлыгы итеп 4 нче Совет бермандатлы сайлау округыннан депутат Кузнецова Рушания Фәрит кызын сайларга.

2.«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясындагы 1 өлеше, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 41 статьясы 5 өлеше нигезендә Багай авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе итеп Кузнецова Рушания Фәрит кызын билгеләргә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Багай авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга:http://bagaev-kaybici.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге адрес буенча:http://pravo.tatarstan.ru. һәм «Кайбыч таңнары» газетасында бастырып чыгарырга.

4.Әлеге карар кабул ителгән көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Багай авыл җирлеге Советы
утырышында рәислек итүче
2 нче Үзәк бермандатлы сайлау
округы депутаты

Камалова Г.Г.